ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
САРМАШ-БАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
САРМАШ-БАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**03.08.2018** Сармаш-Баш ав. № 17

**Басма агитация материалларын**
**урнаштыру өчен махсус урыннар бүлеп**
**бирү һәм җиһазлау турында**

«Сармаш-Баш авыл җирлегенең вәкиллекле органнарына депутатларны өстәмә сайлаулар буенча басма сайлау алды материаллары урнаштыру өчен һәр сайлау участогы территориясендә махсус урыннар исемлеге турында» Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының территориаль сайлау комиссиясе тәкъдимен карап, «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 54 статьясы 7 пункты, 2007 елның 07 маендагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 64 статьясы 8 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Сармаш-Баш авыл җирлеге башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 54 статьясы 7, 8, 10 пунктлары нигезендә 2018 елның 09 сентябрендә Сармаш-Баш авыл җирлегенең вәкиллекле органнарына депутатларны өстәмә сайлаулар буенча сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Сармаш-Баш авыл җирлеге сайлау участогы территориясендә махсус урыннар бүлеп бирергә һәм җиһазларга.
2. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Сармаш-Баш авыл җирлеге сайлау участоклары территориясендә сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру урыннары исемлеген кушымта нигезендә расларга.
3. Әлеге карарны Зәй муниципаль районы территориаль сайлау комиссиясенә җибәрергә.
4. Карарны Сармаш-Баш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешенә контрольне үз өстемдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе**
**Вазыйфаларын башкаручы** **Р.М. Фәсхетдинов**

Зәй муниципаль районы Сармаш-Баш авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 2018 елның 3 августындагы 17 номерлы карарына кушымта.

Татарстан Республикасы Зәй районы сайлау участоклары территориясендә сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урыннар (мәгълүмат стендлары)

| № п/п | Сайлау участогының номеры | Басма агитация материалларын урнаштыру урыннарының адресы |
|---|---|---|
| 1. | 1487 | ТР, Зәй районы, Сармаш-Баш ав., Октябрь ур., 41а й. – кибет бинасы (килешү буенча) |
| | | ТР, Зәй районы, Кәдек ав., Клуб ур. – кибет бинасы (килешү буенча) |
| | | ТР, Зәй районы, Федоровка ав., Клуб ур., 27а й.– ФАП бинасы (килешү буенча) |